| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2017 ел, 17 февраль | № 98 |

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы; 2016 ел, 9. апрель, 210 нчы; 2016 ел, 21 ноябрь, 857 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 2 058,7 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 524,4 млн.сум:<br>2014 ел – 20,0 млн.сум;<br>2015 ел – 97,3 млн.сум;<br>2016 ел – 87,1 млн.сум;<br>2017 ел – 121,8 млн.сум;<br>2018 ел – 106,2 млн.сум; |

| | |
|---|---|
| | 2019 ел – 46,0 млн.сум;<br>2020 ел – 46,0 млн.сум;<br>федераль бюджет акчасы – 197,2 млн.сум:<br>2017 ел – 41,8 млн.сум;<br>2018 ел – 155,4 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль бюджетлар акчасы – 5,1 млн.сум:<br>2014 ел – 3,3 млн.сум;<br>2015 ел – 1,8 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш акчалар – 1 332,0 млн.сум:<br>2014 ел – 0,0 млн.сум;<br>2015 ел – 250,0 млн.сум;<br>2016 ел – 779,2 млн.сум;<br>2017 ел – 202,8 млн.сум;<br>2018 ел – 100,0 млн.сум;<br>2019 ел – 0,0 млн.сум;<br>2020 ел – 0,0 млн.сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Программада Татарстан Республикасы терииториясендә туристлык-рекреация һәм автотуристлык кластерларын төзү күздә тотыла.<br>Әлеге чаралар, төзелә торган кластерлар «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмын үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасына кертелгән очракта, тормышка ашырылачак.<br>Программаның әлеге чараларын финанслау күләмнәре кластерларның проект документларын, Татарстан Республикасы бюджеты акчасының капитал салулар планын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 2 058,7 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 524,4 млн.сум:
2014 ел – 20,0 млн.сум;
2015 ел – 97,3 млн.сум;

2016 ел – 87,1 млн.сум;
2017 ел – 121,8 млн.сум;
2018 ел – 106,2 млн.сум;
2019 ел – 46,0 млн.сум;
2020 ел – 46,0 млн.сум;
федераль бюджет акчасы – 197,2 млн.сум:
2017 ел – 41,8 млн.сум;
2018 ел – 155,4 млн.сум;
билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль бюджетлар акчасы – 5,1 млн.сум:
2014 ел – 3,3 млн.сум;
2015 ел – 1,8 млн.сум;
билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы – 1 332,0 млн.сум:
2014 ел – 0,0 млн.сум;
2015 ел – 250,0 млн.сум;
2016 ел – 779,2 млн.сум;
2017 ел – 202,8 млн.сум;
2018 ел – 100,0 млн.сум;
2019 ел – 0,0 млн.сум;
2020 ел – 0,0 млн.сум.
Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\98.docx